КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 октябрь г.Казань № 915

«Татарстан Республикасы экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында

Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Система) булдырырга.

2. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгын – Системаның операторы һәм функциональ заказчысы, шулай ук Системада эшкәртелә торган мәгълүматка ия булучы итеп;

«Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесен – Системаның дәүләт заказчысы һәм техник операторы итеп.

4. Республика башкарма хакимият органнарына, Система турындагы нигезләмәгә таянып, Системаның эшләве өчен Системада мәгълүматлар, документлар, материаллар урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, физик һәм юридик затларга, Система турындагы нигезләмәгә таянып, Системаның эшләве өчен Системада урнаштыруга мәгълүматлар, документлар, материаллар җибәрүне тәэмин итәргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 23 октябрь, 915 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында
нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкәсе һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендәге стратегияне раслау турында» 2021 ел, 18 август, 748 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкәсе һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендәге стратегия нигезендә эшләнде һәм «Татарстан Республикасы экология һәм табигатьтән файдалану тармагының цифрлы платформасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Система) эксплуатацияләү һәм үстерү тәртибен билгели.

1.2. Система булдыру максатлары:

Татарстан Республикасы милкендәге табигать ресурслары белән эш итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функциясен гамәлгә ашыру;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү;

табигать ресурсларын рациональ файдалануны һәм ярлылануны кисәтүне тәэмин итү;

әйләнә-тирә мохитнең торышын контрольдә тоту һәм аның тенденцияләрен фаразлау;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны кабул итү, эшкәртү, саклау һәм тапшыру өчен бердәм ресурс булдыру;

процессларны Системага күчерү һәм Система кысаларында тышкы ресурсларга тиз арада мөрәҗәгать итү юлы белән агымдагы эш барышлары срокларын кыскарту ярдәмендә Министрлыкның эш барышын оптимальләштерү;

Системаның ярдәмче системалары арасында үзара хезмәттәшлекне оештыру юлы белән Министрлык бүлекчәләре арасында мәгълүмат алмашу срокларын кыскарту.

II. Система кысаларында мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар

2.1. Система кысаларында мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар (алга

таба – Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар):

Системаның операторы (функциональ заказчысы) – Министрлык;

Системаның дәүләт заказчысы (техник операторы) – «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

тәэмин итүчеләр – Системада урнаштыру өчен белешмәләр, документлар, материаллар җибәрүче федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар;

файдаланучылар – Системада урнаштырылган белешмәләрне, документларны, материалларны алырга хокуклы федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар. Кулланучылар Системаның операторы (функциональ заказчысы) тарафыннан бирелгән Системадан файдалану мөмкинлеге кысаларында Системага тоташалар.

2.2. Системаның операторы (функциональ заказчысы):

Системаны эксплуатацияләү, шул исәптән аның мәгълүматлар базаларындагы мәгълүматны эшкәртү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

Системаны эксплуатацияләүнең һәм үстерүнең оештыру ягыннан, норматив һәм методик яктан тәэмин ителеше булуны һәм Системаны алып баруны оештыруны тәэмин итә;

үз вәкаләтләре чикләрендә белешмәләрне, документларны һәм материалларны Системада урнаштыруны, шулай ук Системада урнаштырылган белешмәләр, документлар, материаллар арасында элемтәләр булдыруны тәэмин итә;

файдалану хокукларын чикләүнең рольле моделен кулланып, Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның Системада урнаштырылган белешмәләрдән, документлардан, материаллардан файдалану хокукын билгели;

Системаны модернизацияләү кирәклеге барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлегендә кулланыла торган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларын булдыру, модернизацияләү һәм (яки) сатып алу чараларын планлаштыру һәм гамәлгә ашыру, проект заявкасына эксперт бәя бирү тәртибе нигезендә Системаны модернизацияләүгә проект заявкасын Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына җибәрә;

Системаны модификацияләү (модернизацияләү), аның эшкә сәләтен (эшләвен) тәэмин итү, Системадагы мәгълүматны саклау максатларында һәм Системаның эшчәнлегенә бәйле башка максатларда техник таләпләр проектларын, техник биремнәрне, спецификацияләрне һәм товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен файдалануның махсус хокукын һәм (яки) хокукын сатып алу өчен кирәкле башка документларны Системаның дәүләт заказчысы (техник операторы) тарафыннан тапшырылган көннән биш эш көне эчендә

килештерә;

Системадагы шәхси мәгълүматларны эшкәртүне оештыра һәм гамәлгә ашыра, аларның сакланышын тәэмин итә, шулай ук шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатларын, эшкәртелергә тиешле шәхси мәгълүматлар составын, шәхси мәгълүматлар белән кылына торган гамәлләрне (операцияләрне) билгели;

эшкәртелә һәм Системда чыгарыла торган мәгълүмат өчен җавап бирә;

Системада мәгълүмат урнаштыру һәм актуальләштерү мәсьәләләре буенча тәэмин итүчеләрнең эшчәнлеген координацияли.

2.3. Системаның дәүләт заказчысы (техник операторы) Системаны һәм аның элементларын булдыру, модификацияләү (модернизацияләү), аларның эшкә сәләтен (эшләвен) тәэмин итү максатларында һәм Системаның һәм аның элементларының эшләвенә бәйле башка максатларда товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләреннән файдалануның махсус хокукын һәм (яки) файдалану хокукын сатып алуны гамәлгә ашыра.

2.4. Тәэмин итүче түбәндәгеләрне тәэмин итә:

үз компетенцияләре чикләрендә Системада урнаштыру өчен әлеге Нигезләмәдә каралган белешмәләрне, документларны, материалларны җыю, документлаштыру, эшкәртү, системалаштыру, исәпкә алу һәм электрон рәвештә җибәрүне;

Системада урнаштыру өчен җибәрелә торган белешмәләрнең, документларның, материалларның дөреслеген, тулылыгын һәм актуальлеген;

мәгълүмат иминлегенең оештыру ягыннан һәм техник таләпләре үтәлешен.

2.5. Кулланучы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

мәгълүмат иминлегенең оештыру ягыннан һәм техник таләпләре үтәлешен;

Системада урнаштырылган белешмәләрне, документларны, материалларны бирүгә рәсми сорау формалаштыруны.

## III. Системаның структурасы һәм функциональлеге

3.1. Система модульле структурага ия һәм өч төп функциональ элементтан тора: «Җир асты байлыклары» ярдәмче системасы, «Күзәтчелек» ярдәмче системасы һәм «Экомониторинг» ярдәмче системасы.

3.2. «Җир асты байлыклары» ярдәмче системасында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларны, казылмалар чыгу урыннарын һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен исәпкә алу; Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Гомумтаралган файдалы казылмалар запаслары буенча республика комиссиясе беркетмәләрен исәпкә алу; җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияләр гамәлләре срокларын һәм лицензия килешүе шартларын үтәү срокларын контрольдә тоту; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар, җир асты суларын файдалану, шулай ук җир асты корылмаларын төзү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 февраль, 171 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар

тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар, җир асты суларын файдалану, шулай ук җир асты корылмаларын төзү тәртибенең 2 пункты шартларына җир кишәрлегенең туры килүен билгеләү; гомумтаралган файдалы казылмалардан файдалану нияте турында хәбәрнамәләрне теркәү; җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы лицензиясенә үзгәрешләр кертүгә һәм аларны исәпкә алуга гаризалар кабул итү функцияләре гамәлгә ашырыла.

3.3. «Күзәтчелек» ярдәмче системасында төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) һәм төбәк дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кысаларында контроль (күзәтчелек) чараларын планлаштыру; административ хокук бозу вакыйгалары ачыкланганда профилактик чаралар, план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр, административ тикшерүләр үткәрү; барып тикшерүләр үткәрү, план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр нәтиҗәләре буенча акт, тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган табигатьне саклау законнарын бозуларны бетерү турында күрсәтмә, административ җәза билгеләү турында карар рәсмиләштерү, зыянның исәп-хисабын һәм башка документларны бирү; штрафлар түләү срокларын контрольдә тоту функцияләре гамәлгә ашырыла.

3.4. Экомониторинг» ярдәмче системасында атмосфера һавасын пычратуның потенциаль чыганакларын автомат билгеләү; мәгълүматларны кулдан керткәндә атмосфера һавасын пычратуның потенциаль чыганакларын оператив автомат билгеләү һәм атмосфера һавасы пычрануның фон дәрәҗәсен исәпләү; атмосфера һавасы пычрану күрсәткечләре югары булган карталарны төзеп, атмосфера һавасы пычрану дәрәҗәсе югары булган зоналарны модельләштерү; сынауларны кулдан сайлап алганда һәм лабораториядә тикшерүләр үткәргәндә микъдари химик анализ беркетмәләрен Системага кертү; тышкы кулланучыларның шәхси кабинетында эшләү функцияләре гамәлгә ашырыла.

3.5. Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән шартларда Системаның эшләвен тәэмин итә. Системада урнаштырыла торган белешмәләрнең, документларның, материалларның составы Системаның операторы (функциональ заказчысы) тарафыннан билгеләнә.

3.6. Система модификацияләнгән (модернизацияләнгән) булырга мөмкин.

3.7. Белешмәләр, документлар, материаллар Системада аның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән структурасы нигезендә урнаштырыла.

3.8. Системада мәгълүмат алмашу, шул исәптән электрон төрдә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм дәүләт функцияләрен һәм муниципаль функцияләрне башкару өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктураны кулланып, шулай ук ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдалану юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.9. Системаның түбәндәгеләр белән бәйле интеграцион механизмнары бар:

ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы;

«Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү буенча автоматлаштырылган система» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны исәпкә алуны программа-техник тәэмин итү;

«Россия почтасы» акционерлык җәмгыятенең «Электрон почта системасы»

мәгълүмат системасы;

Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы;

«Татарстан Республикасының экологик картасы» геомәгълүмат системасы;

«Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасы;

башка мәгълүмат системалары (кирәк булганда).

3.10. Системада урнаштырылган белешмәләр, документлар, материаллар конфиденциаль булып тора. Системаның операторы (функциональ заказчы) карары буенча ачык мәгълүмат Системаның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтының һәркем файдалана алырлык өлешендә (алга таба – Системаның Белешмәләр порталы) бастырыла.

## IV. Система кысаларында мәгълүмати хезмәттәшлек

4.1. Системада Мәгълүмати аралашуда катнашучылар арасында мәгълүмат алмашу электрон формада гамәлгә ашырыла.

4.2. Системаның операторына (функциональ заказчысына) тәэмин итүчеләрдән алынган Система белешмәләреннән, документларыннан, материалларыннан файдалану аларга үзгәрешләр кертү мөмкинлегеннән тыш бирелә.

4.3. Системаның дәүләт заказчысына (техник операторына) Системаны файдалану нәтиҗәлелеген һәм динамикасын анализлау өчен Системаның барлык компонентлары буенча метрикалардан, шулай ук берләштерелгән мәгълүматлардан файдалану мөмкинлеге бирелә.

4.4. Белешмәләрне, документларны, материалларны Системага урнаштыру, шулай ук аларны теркәү һәм исәпкә алу электрон рәвештә гамәлгә ашырыла.

## V. Системага файдалану мөмкинлеген бирүгә карата таләпләр

5.1. Файдаланучыларның Системада урнаштырылган белешмәләрдән, документлардан, материаллардан файдалану мөмкинлеге, түләү алмыйча, Системаның Белешмә порталыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

5.2. Системаның Белешмәләр порталыннан файдаланып кулланыла торган белешмәләр, документлар, материаллар исемлеге әлеге Нигезләмәнең 3.5 пункты буенча билгеләнә.

5.3. Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларга Системадан файдалану мөмкинлеге бирeләчәк шартларны Системаның операторы (функциональ заказчысы) билгели.

5.4. Системада Системаны алып баруны гамәлгә ашыручы Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның, тәэмин итүчеләрнең файдалану мөмкинлеген исәпкә ала торган язуларын булдыру өлешендә Системадан файдалану мөмкинлеген оештыруны Системаның операторы (функциональ заказчысы) билгели.

Системаның операторы (функциональ заказчысы) Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыга файдалану мөмкинлеген бирү өчен заявка формалаштыра, заявкада фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), электрон почтасы, роле, файдалану

хокукы (уку, редакцияләү, бетерү һ.б.) күрсәтелә. Системаның операторы (функциональ заказчысы) Системаның дәүләт заказчысына (техник операторына) заявка җибәрә. Системаның дәүләт заказчысы (техник операторы) биш эш көне эчендә Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыга файдалану мөмкинлеген бирүне тәэмин итә.

Файдалану мөмкинлеге хокукларын биргәннән соң, Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучы авторизация узарга мөмкин.

5.5. Системадан файдалану мөмкинлеген бирү шартлары:

техник мөмкинлек булу;

мәгълүмати иминлек таләпләре үтәлешен тәэмин итү.

## VI. Системада эшләгәндә мәгълүмати иминлекне тәэмин итүгә карата таләпләр

6.1. Система Техник һәм экспорт контроле федераль хезмәтенең «Дәүләт мәгълүмат системаларындагы дәүләт серен тәшкил итмәгән мәгълүматны яклау турындагы таләпләрне раслау турында» 2013 елның 11 февралендәге 17 номерлы боерыгы нигезендә аттестацияләргә тиеш.

6.2. Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар Системаны аттестацияләүгә карата таләпләр нигезендә Системада эшләгәндә үз эш урыннарында мәгълүматны саклауны тәэмин итәргә тиеш.

6.3. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм саклауга карата мәгълүмати иминлек буенча таләпләрне бозган өчен Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар законнарда каралган тәртиптә җавап бирә.

6.4. Барлык мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларга Системадан файдалану өчен авторизацияләү чараларын (шул исәптән логиннарны һәм парольләрне) өченче затларга бирергә тыела.

6.5. Тәэмин итүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә белешмә, документлар, материалларның тулылыгы, дөреслеге һәм Системага урнаштыру өчен үз вакытында җибәрү өчен җавап бирә.

6.6. Системаның операторы (функциональ заказчысы) Системадагы мәгълүматны саклауга карата таләпләрне билгели, моның өчен ул түбәндәгеләрне башкара:

мондый мәгълүматка карата хокуксыз файдаланудан, бетерүдән, модификацияләүдән, блоклаудан, күчерүдән, бирүдән, таратудан, шулай ук башка хокукый булмаган гамәлләрдән сакланырга тиешле мәгълүматны билгеләү;

Система туры килергә тиешле норматив хокукый актларны, методик документларны һәм милли стандартларны анализлау;

мәгълүматны саклау турындагы таләпләр нигезендә Системаны классификацияләү;

Системада мәгълүмат иминлеген бозуга китерергә мөмкин булган мәгълүмат иминлеген билгеләү һәм алар нигезендә мәгълүмат иминлегенә куркыныч янау моделен эшләү;

Системадагы мәгълүматны саклау буенча мәгълүмат системасына (ярдәмче системага) карата таләпләрне билгеләү.

6.7. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү,

мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы мәгълүматны саклауга карата билгеләнгән таләпләрнең үтәлешенә кагылышлы өлештә иминлекне тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән һәм техник разведкаларга һәм мәгълүматны техник саклауга каршы тору өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән мәгълүматны саклау системасына техник биремне һәм мәгълүмат иминлегенә янаулар модельләрен килештерүне оештыра.